РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

***Постановление*** ***Карар***

__16.01.2026___ **Чистай шәһәре** **№__13__**

Чистай шәһәре предприятиеләреннән
үзәк су агызу системасына һәм
«Чистай-Водоканал» АҖ чистарту
корылмаларына керә торган агып төшүче
суларның составы буенча су агызу
нормативларын билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Суны, агып төшүче суларны коммерциячел исәпкә алуны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 04 сентябрендәге 776 номерлы карары, «Агып төшүче суларның составын һәм үзлекләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, «Чистай-Водоканал» АҖ абонентлары өчен пычраткыч матдәләрне агызу нормативларын исәпләп чыгып, «Чистай шәһәре»муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 01.01.2026 елдан 01.01.2028 елга кадәр Чистай шәһәре предприятиеләреннән «Чистай-Водоканал» АҖнең үзәк су агызу системасына һәм чистарту корылмаларына керә торган ташландык сулар составы буенча су агызу нормативларын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе А.Р. Хаматов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Башкарма комитетының
__16.01.2026__№__13__ карарына
1 нче кушымта

Чистай шәһәре предприятиеләреннән үзәк су агызу системасына һәм «Чистай-Водоканал» АҖ чистарту корылмаларына керә торган агып төшүче суларның составы буенча су агызу нормативлары

| № | Агып төшүче сулар составы күрсәткечләре | Рөхсәт ителә торган концентрациянең расланган нормативлары, мг/л |
|---|---|---|
| 1 | ХПК | 500 |
| 2 | БПКполн | 300 |
| 3 | Аммоний-ион | 1,6 |
| 4 | Үлчәүле матдәләр | 300 |
| 5 | Гомуми тимер | 0,5 |
| 6 | Марганец | 0,01 |
| 7 | Бакыр | 0,001 |
| 8 | Нефть продуктлары | 0,09 |
| 9 | Никель | 0,01 |
| 10 | АПАВ | 0,25 |
| 11 | Сульфат-анион | 100 |
| 12 | Коры калдык | 1000 |
| 13 | Фосфатлар | 0,163 |
| 14 | Хлоридлар | 200,66 |
| 15 | Хром (6+) | 0,005 |
| 16 | Цинк | 0,01 |